КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 май г.Казань № 400

Татарстан Республикасында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына таянып, стандарт торак төзү максатларында территорияләрне үзләштерү турындагы шартнамәләр яки стандарт торак төзү максатларында территорияләрне комплекслы үзләштерү турындагы шартнамәләр нигезендә төзелгән стандарт торак сатып алуга хокукы булган гражданнар тарафыннан стандарт торак сатып алуның кайбер мәсьәләләре турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясы нигезендә, Татарстан Республикасында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына таянып, стандарт торак сатып алуга хокукы булган гражданнар тарафыннан стандарт торак төзү максатларында территорияләрне үзләштерү турындагы шартнамәләр яки стандарт торак төзү максатларында территорияләрне комплекслы үзләштерү турындагы шартнамәләр нигезендә төзелә торган яки төзелгән стандарт торак сатып алуны оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында стандарт торак сатып алуга хокукы булган гражданнар категорияләре исемлеген;

Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары тарафыннан гариза бирүче гражданнарның стандарт торак сатып алуга хокукы булган гражданнарның билгеләнгән категорияләренә туры килүен тикшерү, мондый гражданнарның исемлекләрен төзү һәм раслау, әлеге исемлекләргә үзгәрешләр кертү тәртибен;

Татарстан Республикасы буенча стандарт торак сатып алуга хокукы булган гражданнар исемлекләренә кертелгән гражданнарның җыелма реестрын алып бару һәм әлеге реестрдагы мәгълүматларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә стандарт торак төзү максатларында территорияләрне үзләштерү турында шартнамәләр яки стандарт торак төзү максатларында территорияләрне комплекслы үзләштерү турында шартнамәләр төзегән юридик затларга бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын Татарстан Республикасы буенча стандарт торак сатып алуга хокукы булган гражданнар исемлекләренә кертелгән гражданнарның җыелма реестрын формалаштыру һәм әлеге реестрдагы мәгълүматларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә стандарт торак төзү максатларында территорияләрне үзләштерү турында шартнамәләр яки стандарт торак төзү максатларында территорияләрне комплекслы үзләштерү турында шартнамәләр төзегән юридик затларга бирү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына гариза бирүче гражданнарның стандарт торак сатып алуга хокукы булган гражданнарның билгеләнгән категорияләренә туры килүен тикшерү, мондый гражданнарның исемлекләрен формалаштыру һәм раслау, әлеге исемлекләргә үзгәрешләр кертү эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы; 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче; 2016 ел, 10 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 13 декабрь, 925 нче; 2017 ел, 6 март, 127 нче; 2017 ел, 26 май, 309 нчы; 2017 ел, 14 ноябрь, 867 нче; 2018 ел, 4 июль, 545 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 10 декабрь, 1107 нче; 2018 ел, 14 декабрь, 1135 нче; 2019 ел, 16 апрель, 301 нче; 2019 ел, 21 май, 416 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 13 июль, 576 нчы; 2019 ел, 12 октябрь, 907 нче; 2020 ел, 10 февраль, 83 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3 нче пунктның 3.3.1 нче пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы буенча стандарт торак сатып алуга хокукы булган гражданнар исемлекләренә кертелгән гражданнарның җыелма реестрын формалаштыра һәм әлеге реестрдагы мәгълүматларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә стандарт торак төзү максатларында территорияләрне үзләштерү турында шартнамәләр яки стандарт торак төзү максатларында территорияләрне комплекслы үзләштерү турында шартнамәләр төзегән юридик затларга бирә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин